# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге муниципаль берәмлегенә кергән Татар Такталы торак пунктында 2025 елга үзара салым кертү турында

24.10.2024 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлегегенә кергән Татар Такталы торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАРЫ:

1.Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлегегенә кергән Татар Такталы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

1) Татар Такталы торак пунктында Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктыртуын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

2) Татар Такталы торак пункты территориясен төзекләндерү (грейдировка, юлларны кардан чистарту,уләннәрне чаптыру, агачларны кистерү (ягулык-майлау материаллары, МТЗ-82 тракторы өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү));

3) Татар Такталы торак пунктында Каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (ягулык

3. Әлеге карарны Аграмак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм http:// www. spasskiy.tatarstan.ru Спас муниципаль районы рәсми сайтының Аграмак авыл җирлеге битендә, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Спас муниципаль районы
Аграмак авыл җирлеге башлыгы: Р.Т. Галәветдинова

СОВЕТ АГРАМАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «АГРАМАКОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА